| | |
|---|---|
| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>СТАРОМЕНЗЕЛЯБАШСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>САРМАНОВСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>САРМАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>ИСКЕ МИНЗӘЛӘБАШ<br>АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2025 ел 22 нче декабрь № 24

“Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районы
Иске Минзәләбаш авыл җирлеге муниципаль
хезмәткәрләрен акчалата тәэмин итү турында"
нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарә органнары депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының, контроль-хисап органнары рәисләренең, Рәис урынбасарларының, Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләр органнарының аудиторларының, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәтенә түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында» 28.03.2018 ел № 182 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына үзгәрешләр кертү хакында» 25.11.2025 ел, № 994 карары нигезендә Иске Минзәләбаш авыл җирлеге башкарма комитеты, КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Иске Минзәләбаш авыл җирлеге Башкарма комитетының 10.08.2018 ел № 8 карары белән расланган «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Иске Минзәләбаш авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләрен акчалата тәэмин итү турында» гы нигезләмәгә (12.12.2018 елгы № 17, 01.10.2020 елгы № 9, 28.06.2024 елгы № 10, 07.11.2024 елгы № 16, 30.04.2025 елгы № 9 ) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- 1 нче кушымтаның 2 пунктында «15 389» санын «16 928» санына алмаштырырга.

2. Әлеге карар 2026 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

3. Әлеге карарны «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм «Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең «Интернет»мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

Иске Минзәләбаш авыл җирлеге
Башкарма комитет җитәкчесе: А.Н.Габдрахманов